ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 октября 2016 г. № 5458

Башкарма комитетның 2010 елның 23 мартындагы 1808 нче карары белән расланган эш урынынан бирелүче торак биналарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 53 маддәсе, Башкарма комитетның «Муниципаль махсуслаштырылган торак фондында хезмәт урынынан торак урыннары бирелә торган гражданнарның категорияләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 маендагы 2440 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2010 елның 23 мартындагы 1808 нче карары белән расланган эш урынынан бирелүче торак биналарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) эшләгән чорда эш урынынан торак бина биргән дәүләт органы (җирле үзидарә органы), предприятие (учреждение) белән хезмәт мөнәсәбәтләрен дәвам итүче затлар өчен дәүләт органы (җирле үзидарә органы), предприятие (учреждение) җитәкчесенең үтенеч язуы буенча.»;

2) 4 пунктта «Башкарма комитетның торак йортларны исәпкә алу идарәсе» сүзләрен «Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең торакны үстерү бүлеге» сүзләре белән алыштырырга;

3) 5 пунктта «Башкарма комитетның торак йортларны исәпкә алу идарәсе» сүзләрен «Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең торакны үстерү бүлеге» сүзләре белән алыштырырга;

4) 6 пунктта «Башкарма комитетның торак йортларны исәпкә алу идарәсе тарафыннан» сүзләрен «Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең торакны үстерү бүлеге тарафыннан» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин